# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 5 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында" 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 8 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) исемендә "Министрлар Кабинеты" сүзләрен "башкарма хакимияте органнары" сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацта "Халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты" сүзләрен "1. Халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары" сүзләренә алмаштырырга;

в) уникенче абзацта "кирәк очракта" сүзләреннән соң "федераль" сүзен өстәргә;

г) унөченче һәм ундүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм зарарсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә үз компетенциясе чикләрендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру;

азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм зарарсызлыгы, халыкның сәламәтлеге мониторингын үз компетенциясе чикләрендә үткәрү;";

д) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналарының, аларның санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе булса, чикләрен һәм режимын билгеләү.";

е) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

"2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан яисә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ул вәкаләт биргән органы (органнары) тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 4 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 6 статьяның 2 өлешендә "мониторингы" сүзеннән соң "федераль" сүзен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 20 июле
№ 62-ТРЗ